**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
Азнакай
муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ

ул. Советская, д. 81 , село Чубар-Абдуллово
Азнакаевского муниципального района,
423323
Тел. (факс) (85592)38-7-37
Chabd.Azn@tatar.ru

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
Тел. (факс) (85592) 38-7-37
Chab.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

От «05» октября 2019 года № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең Чубар-Абдул торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 16 октябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә Совет урамы 1 йорттан 119 йотка кадәр, Яшьләр урамы 1 йорттан 13 йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 17 октябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: Чапаев урамы 1 йорттан 48 йотка кадәр, Комсомол урамы 1 йорттан 28 йортка кадәр

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул торак пункытында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 16 октябрь 2020 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 17октябрь 2020 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Чубар-Абдул авылы, Совет ур. , 85 йорт, Чубар-Абдул авыл мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 10 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Чубар-Абдул авылы, Совет урамы, 81йорт

- сайлау хокукына ия булган Чубар-Абдул торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Чубар-Абдул торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга гравий җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Чубар Абдул авылында Совет урамына:
- Чубар-Абдул авылында («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү.

« РИЗА»  «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чубар-Абдул авылы, Совет ур., 85 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык:  Н. Ә. Фәтхетдинов